УДК 930.2

# СЕУЛ ШӘҺӘРЕНДӘГЕ «НОГМАНИЯ» МӘЧЕТ-МӘКТӘБЕ ҺӘМ АНЫҢ ИГАНӘЧЕСЕ ГАБДЕЛХАК НОГМАН

***Ш.Ф. Садыйков***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*mergen777@mail.ru*

Бүгенге көндә дөньяның кайсы гына почмагына барма, татар кешесен очратырга мөмкин. Аларның теге яки бу җирдә урнашуының үз тарихы һәм төрле сәбәпләре бар. Татар кешесен язмыш кая гына китермәсен, ул, беренче чиратта, милләттәшләре, дин кардәшләре белән берләшә, мөселман мәхәлләсен оештыра. Бу хәл төрле тарихи чорларда татарларга үзаңын, динен һәм телен саклап калырга ярдәм иткән. Кореяга барып җиткән милләттәшләребез дә бу кагыйдәләрдән читтә калмаганнар. Әлеге мәкаләдә «Милли байрак» газетасы материалларына таянып, Кижу (Кейджо) (хәзерге Сеул) шәһәрендәге «Ногмания» мәчет-мәктәбе һәм аның иганәчесе Габделхак Ногман эшчәнлеге турында мәгълүмат бирелә. 1926 елда оешкан мәчет-мәктәп озак еллар дәвамында Корея татарларының төп мәгърифәт учагы булып торган, Кижу Идел-Урал төрек-татарлары мәдәнияте җәмгыятенең идарәсе карамагында эшләп килгән. Әлеге газетага таянып, мәктәп эшчәнлегенә караган мәгълүматларны 1944 елга кадәр күзалларга мөмкин.

Бүгенге көндә мөһаҗирлектәге милләттәшләребезнең тарихын өйрәнү татар халкының бай мәдәни мирасын туплау, барлау һәм торгызу юлында иң мөһим эшләрнең берсе. Әлеге мәгълүматлар нигезендә Корея татарларының милли мәгарифе торышы, андагы укыту программалары, укыту тәртипләре, кулланылган дәреслекләр белән танышырга мөмкин. Моннан тыш, аерым педагогларның, иганәчеләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең исемнәрен барлау, мәктәпнең оешу тарихын күзаллау мөмкинлеге туа. Мәктәп белән бәйле яңа мәгълүматларны, төрле фикерләрне, аерым фотоларны бастырып чыгару татар халкының асылын ачыкларга, бердәмлеген ныгытырга ярдәм итә.

**Ачкыч сүзләр:** Кижу, Габделхак Ногман, «Ногмания» мәктәбе, «Милли байрак» газетасы, милләт, татар мәгарифе, мөһаҗирлек.

*© Садыков Ш.Ф., 2023*

Татарлар Ерак Көнчыгышка XIX йөзнең ахыры – XX йөзнең башында күченеп китә башлыйлар. Аларның әлеге илләргә сәфәре, беренче чиратта, Көнчыгыш Кытай тимер юлы салына башлау белән бәйле була. Нәтиҗәдә тимер юл буендагы Кытай шәһәрләрендә – Маньчжурия, Хайлар, Харбинда татарлар оешып яши башлый.

Революция һәм гражданнар сугышы дулкыны 1917 елдан Кытайга мөһаҗирләрнең яңа төркемнәрен алып килә. Алар арасында төрле төбәктән, төрле катламга караган кешеләр – игенчеләр, приказчиклар, укытучылар, хәрбиләр күп була. Маньчжуриядәге шартлардан канәгать булмыйча, шактыйлары Япониягә юл тота. Монда аларның күпчелеге актив рәвештә сәүдә эше белән шөгыльләнә башлый. Шулай итеп, 1935 елга Ерак Көнчыгыштагы 10 мең мөһаҗирнең 2 меңе Япониядә яши. Япон хөкүмәте, үз чиратында, төрки-татар эмиграциясен яхшы кабул итә. Бу иң беренче чиратта японнарның мөселманнар һәм ислам дине белән кызыксынулары һәм аларга карата уңай сәясәт алып барулары белән бәйле була. 1927 елда татарларга милли мәктәпләр булдырырга, мәчетләр төзергә рөхсәт бирелә. Ерак Көнчыгыш мөһаҗирләре өчен чыгып килгән «Милли Байрак» газетасындагы милли мәсьәләләргә кагылышлы мәкаләләр төрки-татар эмиграциясенә урындагы хакимият тарафыннан шактый киң мөмкинлекләр бирелгәнлеге турында сөйли. Әлеге газетада төрки-татар мәктәпләренең эшчәнлеген, дәреслекләр мәсьәләсен, милли мәгариф һәм аның бурычларын, туган телне, тарихны, динне саклау һәм укыту, милли тәрбия һ.б. проблемаларны яктыртуга шактый урын бирелә. Газетада иң күп күтәрелгән мәсьәлә – Ерак Көнчыгышта татар мәктәпләренең эшчәнлеге. Бу мәкаләләрдә аерым мәктәпләрдә укыту һәм тәрбия эше, аның эчтәлеге, яңа мәктәп биналарын ачу, аларда белем бирүче укытучылар, имтихан нәтиҗәләре һ.б. турында сөйләнә (Мортазина, 2018: 265). Аерым алганда, Харбиндагы «Гыйнаять» мәктәбе, Мукден, Хайлар, Нагоя һ.б. япон шәһәрләрендәге татар мәктәпләре турындагы язмалар зур кызыксыну уяталар.

Әлеге мәкаләдә Киҗу шәһәрендә ачылган «Ногмания» мәчет-мәктәбе һәм аның иганәчесе Габделхак Ногман турында мәгълүмат бирү максат ителә. Японнар Киҗу («башкала ныгытмасы») дип хәзерге Кореядагы Сеул шәһәрен атаганнар. Тарихтан билгеле булганча, 1910–1945 еллар аралыгында Корея Япон империясе хакимияте астында яшәүче ил була. Шунлыктан андагы мәктәпләр татарларның Ерак Көнчыгыштагы һәм Япониядәге мәгариф системасына кергән дип әйтә алабыз. Моннан тыш, Корея җирлегендә татар диаспорасының иң күпчелеге нәкъ Киҗу шәһәрендә яшәгән. Татар кешесен язмыш кая гына китермәсен, ул беренче чиратта милләттәшләре, дин кардәшләре белән берләшә, мөселман мәхәлләсен оештыра башлый. Кореяга барып җиткән татарлар да әлеге кагыйдәдән тайпылмаган.

Кореядагы татарлар язмышы турында Л.Р.Усманова, И.Гыйләҗев, Н.Дәүләт, Р.М.Адутов, М.Таһир мәкаләләрендә беркадәр мәгълүмат очрый. Мәсәлән, Кытайда туып үскән, соңыннан Төркиягә күчеп, озак еллар Әнкарада инженер булып эшләгән Мәхмүт Таһир «Казан утлары» журналында Корея та-

тарлары һәм безне кызыксындырган «Ногмания» мәктәбе буенча белешмә бирә. Аның мәгълүматларына караганда, 1921 елда Японияда бик нык җир тетрәү була. Аннан күчеп киткән татарларның күбесе Кореяга барып чыгалар. Алар төрле эшләргә ялланалар, азрак хәл алганнары кечкенә кибетләр ачып җибәрәләр (30 нчы еллар ахырында бер Сеул шәһәрендә генә дә 28 татар кибете булган). Гомумән алганда, Кореяда татар кибетләренең саны 60 ка якынлашкан. Аларның «Алтай», «Нур», «Казан», «Байкал», «Урал», «Самара», «Болгар» кебек яңгырашлы татар исемнәрен йөртүләре хәзерге көндә дә горурлык хисе тудыра (Таһир, 1990: 178).

Корея татарларының мөселман мохитен булдырудан төп максатлары – уртак дини һәм милли тормыш белән яшәү, балаларын татарча укыту теләге була. Мөселман зираты ачыла, ә 1926 елда Габдулла Ногман акчасына татар җәмгыяте өчен махсус ике катлы бина сатып алына. Аның беренче каты зур зал, идарә утырышлары һәм хезмәтчеләр торыр өчен бүлмәләрдән гыйбарәт булса, икенче катын мәчет гыйбадәтханәсе һәм балалар укый торган мәктәп сыйныфлары били. Химаячесенә бәйле рәвештә «Ногмания» исемен алган мәктәп алты еллык итеп оештырыла, анда төрле елларда Зәйнәп Рәхим, Габдулла Хәким, Разия Дәүләткилде, Халидә Камайлар балаларга белем бирә.

Кижуда дини эшләрне имам Габделкәрим Рәхим башкара. Соңрак аның вазифаларын Габдулла Хәким, Габдулхак Ногман, Мөхәммәт Зариф Янгураз, Гарифулла Гыйззәтләр үти. Кореядагы җәмгыять эшләре белән Габдулла Нурмөхәммәт, Кәрим Сөләйман, Мөхәммәт Зариф, Галим Сәлахетдин, Төркиягә күчү дәверендә Исхак Багдаш, Гыйниятулла Моратлар җитәкчелек итә.

Җомга һәм бәйрәм көннәрендә Кижу татарлары мәчеткә намаз укырга җыела. Зур залда туй һәм бәйрәм тантаналары, дини һәм милли хәтер мәҗлесләре, балаларның күңел ачу уеннары уздырыла. Жырлы-биюле кичәләргә башка шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләр дә килә. Кижудагы татар җәмәгатьчелеге тормышын Ерак Көнчыгышта чыккан газеталар даими рәвештә яктыртып торалар. Татарларның актив эшчәнлеге, бердәмлеге, йолалары, бәйрәмнәре алар белән бергә яшәгән һәм эшләгән кореялылар арасында кызыксыну тудыра, аларның кайберләренең ислам динен кабул итүләренә һәм мөселман кануннары буенча яшәүләренә этәргеч ясый (Таһир, 1990: 178–179).

М.Таһир мәкаләсенә таянып, без Кижуда 1926 елдан «Ногмания» исемле татар мәктәбенең эшләп килүен күрә алабыз. Л.Р.Усманова мәгълүматлары буенча, Кореяда төрки-татар җәмгыяте 1923 елдан соң оешкан. Ул шулай ук мәчет (1926 елдан) һәм «Ногмания» исемле мәктәп эшләве турында яза. Бу мәгълүматларның күпчелеге 1945 елда Рокыя Мөхәммәдиштән[1] сорау алу материалларында искә алына, мәктәпнең исә бары тик исеме генә атала (оешу датасы күрсәтелмәгән) (Усманова, 2005: 100).

[1] Рокыя Мөхәммәдиш (Рокыя Дәүләткилде, 1908–1985), «Милли байрак» газетасы хәбәрчесе, Ерак Көнчыгыштагы Идел-Урал төрек-татар башкарма комитетының дәреслекләр комиссиясе рәисе урынбасары.

Кижу шәһәрендә татар балалары өчен ачылган белем бирү йортлары буенча материаллар шулай ук зур кызыксыну тудыралар. «Милли байрак» газетасында бу темага багышланган берничә мәкалә бар. 1942 елга кадәр чыккан мәкаләләрдә Кижудагы мәктәпне бары тик «Кижу мәктәбе» дип атау каралган. Мәктәпкә «Ногмания» исеме 1943 елда гына бирелә, моңа Ә.Кәримуллин һәм Д.Гайнетдинов язмалары да дәлил булып тора. Алар фикеренчә, 1926 елда Кижу татар җәмгыяте мәктәп һәм мәчет өчен ике катлы зур бинаны арендага ала. Соңрак бу ике катлы зур бина Габделхак Ногман васыять итеп калдырган акчага сатып алына. Иганәчесе хөрмәтенә аны «Мәктәбе Ногмания» дип атый башлыйлар (Кәримуллин, 2019; Гайнутдинов, 2021). «Милли байрак» газетасында 1937, 1938 елларда чыккан Кижу мәктәбендә имтиханнар алуга багышланган мәкаләләр безнең фикерне раслыйлар. Бу язмаларда әлеге мәктәп «Кижу Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте карамагында эшләп килгән дини-милли мәктәп» дип искә алына. Шәкертләр ел саен укытучы, ата-аналар, җәмгыять әгъзалары алдында имтихан тота торган булганнар һәм бу бик зур вакыйга итеп каралган. Аерым очракларда, җәмгыять рәисеннән, җәмгыять әгъзаларыннан тыш, япон кунаклары килү очраклары да күзәтелә. Бу вакытта укучылар аерым сорауларга япон телендә җавап бирә торган булганнар. Моннан тыш, рус һәм инглиз телләрен укыту каралган була. Әмма мәктәптәге укыту эшләре һәм имтихан алу бары тик ана телендә алып барылган. Имтихан үткәрү ел саен бер үк тәртип буенча уза дип әйтсәк, ялгышмабыз. Башта сүзне кыска тәбрик нотыгы белән мөгаллим башлап җибәргән, соңыннан берәр шәкерт тарафыннан Коръән укылган һәм имтихан башланып киткән. Имтихан нәтиҗәләре һәм бәяләмәләре буенча укучыларны икенче уку елына күчерү тәкъдим ителгән. Алтынчы сыйныфны тәмамлаган укучылар шәһадәтнамә алганнар һәм укуларын башка дәүләт мәктәпләрендә дәвам иткәннәр. Әлеге мәктәптә белем бирү башлангыч һәм урта мәктәпләр программасы буенча алып барылган. Шәкертләрнең имтиханыннан соң Коръән укылган, аерым ата-аналар, кунаклар балаларга яхшы белем, дини-милли тәрбия биргән өчен мөгаллимгә рәхмәт сүзләрен җиткергәннәр. Соңыннан укучыларга бүләкләр тапшырылган, хатын-кызлар тарафыннан чәй табыны ясалган, милли ашлар тәкъдим ителгән. Ахырдан мөгаллим белән укучыларның бердәм фотосурәте алынган (Рәс. 1, 2). Үз балаларын татар милләтенең дәвамчылары итеп күргән кунаклар, имтихан нәтиҗәләреннән канәгать булып, шатланып өйләренә кайтып китә торган булганнар (Мохбир, 1937: 3, Мохбир, 1938: 3).

Газета материалларын өйрәнгәндә шул нәрсә күзгә ташлана: сүзнең лексик мәгънәсен көчәйтер өчен, мәкалә авторлары еш кына синоним сүзләр кулланганнар. Мәсәлән, «рәхмәт» һәм «тәшәккүр», «мәҗлес» һәм «мәрасим», «ихтиляль» һәм «инкыйлаб», «сөаль» һәм «сорау» сүзләре еш очрый. Моннан тыш, мәкаләләрдә Кижу шәһәре татарларын аерым очракта «җәмгыять әгъзалары» яисә «мәхәллә әгъзалары» итеп атау да күренгәле.




Рәс. 1. Шәкертләр һәм аларның мөгаллимнәре Габдулла әфәнде Хәким.
Чыганак: «Милли байрак» газетасы, 1937 ел, 23 апрель.




Рәс. 2. Кижуда имтиханнан соң.
Чыганак: «Милли байрак» газетасы, 1938 ел, 5 август.

1942 елда басылып чыккан «Кижуда имтихан» исемле мәкалә бу мәктәпнең тормышы һәм алда булачак үзгәрешләрнең сәбәпләре турында сөйли. Әгәр моңарчы дөнья күргән мәкаләләрдә без имтиханнарның мәктәп бинасында узуларын күзәтсәк, бу елны, бинада төзекләндерү эшләре алып барылу сәбәпле, имтихан Вәлиулла Ибраһим өендә үткәрелә. Имтихан алу тәртибе башка еллардан аерылмый. Имтихан үткәрү өчен мәхәлләнең махсус бинасы, утырып укыр өчен урыннар булмау шәкертләрне дә борчыган. Алар, ата-аналарның, җәмәгатьчелекнең әлеге хәлгә игътибар итәргә тиеш булуларын сөйләп, халыкка мөрәҗәгать иткәннәр. Моннан тыш, әлеге мәкалә нигезендә без мәктәптә яңа укытучы – Рузия Ибраһим килүен күрә алабыз. Моңа кадәр мөгаллим вазифаларын башкарган Габдулла Хәким мәхәлләнең мулласы итеп билгеләнә (Мохбир, 1942: 4).

1943 елда «Милли байрак» газетасында дөнья күргән «Мәсҗид вә мәктәбе «Ногмания»нең ачылу мәрасиме» исемле мәкалә фикер төрлелегенә нокта куя. Мәкалә 1940 елда Кижу шәһәрендә вафат булган милләттәшебез Габделхак Ногманның васыять акчасына торгызылган мәчет һәм мәктәп ачу тантанасына багышланган.

Габделхак Ногманның изге эшләрен һәм яхшылыкларын искә алып, Кижу мөселман җәмгыяте әлеге бинага «Ногмания» исемен бирергә карар кыла. Бу тантана 1943 елның 5 октябрендә көндезге сәгать 1дә зур итеп уздырыла.

Әлеге мәктәпне төзекләндерү, ачу, Шәркый Азиядәге барлык милли-дини идарәләр вәкилләрен мәктәп ачылу тантанасына чакыру һәм, гомумән, әзерлек эшләрен Кижу Идел-Урал төрек-татар мөселманнары мәдәнияте җәмгыятенең идарәсе үз өстенә ала. Нәтиҗәдә әлеге мәктәпне ачуга чит төбәкләрдән шактый күп кеше җыела. Алар арасында: Мукденнан Мәркәз башкарма вәкиле рәисе Әхмәдша әфәнде Гыйззәтуллин, Ерак Көнчыгыш Идел-Урал төрки-татарларының Башкарма комитеты рәисе урынбасары Габделкәрим хәзрәт Рәхим, Хайлар милли идарә рәисе Хәсәнетдин әфәнде Сухе, Кобе Идел-Урал җәмгыяте вәкиле имам Хәсән Кильки, Токио Идел-Урал җәмгыяте рәисе вәкиле Мәхмүд Хуҗа әфәнде була, Тайдиннан, Ноюкидан, Фузаннан һ.б. шәһәрләрдән дә вәкилләр катнаша.

Тантана Кижу җәмгыяте имамы Габдулла Хәкимнең Коръән укуы белән башлана, догалар, тәкъбирләр әйтелә. Мөфти Габделкәрим хәзрәт Рәхим мәчет ишекләренә бәйләнгән тасманы кисеп ала. Мәчеттә Габделхак әфәнде рухына дога укыла, азан әйтелә, намаз үтәлә. Намаздан соң җәмәгать мәктәп бүлмәсенә юл тота. Мәктәп ишегендәге тасма Габделхак әфәндeнең хатыны Шәмсенур ханым тарафыннан киселә. Шуннан соң җыелган халык мәчет-мәктәп укытучыларының һәм хезмәтчеләренең бүлмәләрен карап чыга. Җәмгыять рәисе тарафыннан рәсми рәвештә ачылу тантанасы игълан ителә. Аерым рәвештә Бөек Шәркый Азиядә корбан булган япон гаскәрләре хөрмәтенә бер минут тынлык саклана. Шуннан соң вәкилләргә сүз бирелә, башта вилаять җитәкчелегеннән Кусану сан сүз ала. Соңыннан Мәркәз башкарма рәисе, котлап, тәфсирле нотык сөйли. Өченче сүзне Мәркәз диния шөгъбәсе рәисе ала.

Болардан соң бер-бер артлы Кижу җәмгыяте рәисе, Токио имамы Мөхәммәдәмин хәзрәт, Кобе имамы Хәсән әфәнде Кильки һәм башка вәкилләр шул көннең төп вакыйгасына багышлап сүз сөйлиләр. Ахырдан Кижу җәмгыяте әгъзалары, мөгаллимә Рузия ханым Ибраһим һәм мәктәп шәкертләре котлау сүзләре белән чыгалар. Мәҗлес Шамил әфәнде Ямамото тарафыннан укылган Коръән белән тәмамлана (Мохбир, 1943: 2).

Соңыннан «Ногмания» ачылу белән котларга килгән кешеләр тарафыннан бүләкләр бирелә, иганәләр туплана. Мәсәлән, мәчет өчен Токио ислам җәмгыятеннән, Шәмсенур ханым һәм Шамил әфәнде Ямамотолардан бер палас, Галим әфәнде Сәлахетдиннән мәчеткә бер келәм, Токио Идел-Урал җәмгыятеннән бер Кәлам шәриф (*Коръән*), Габдерәшит хәзрәт Ибраһимовтан үз әсәрләреннән 80 нөсхә дәреслек китаплары, Кобе Идел-Урал җәмгыятеннән 20 данә фәс (баш киеме), аерым затлардан чемодан, рәсемнәр, берничә нөсхә дин дәреслекләре, Шәмсенур ханымнан мәрхүм Габделхак әфәнде Ногманның рәсеме һәм ике дивар сәгате, Кижу шәһәрендәге ханымнардан ашханә әсбаплары бүләк ителә. Шулай ук милләттәшләр арасында «Ногмания» файдасына 8810 иена иганә туплана. Көндезге 1дә башланган тантана кичке 11гә кадәр дәвам итә.

Икенче көнне тантанага килгән вәкилләр аерым автобуста Габделхак Ногманның каберенә барып, мәрхүмнең рухына Коръән укыйлар. Шул көнне кичке сәгать 6да «Ногмания» залында милли кичә оештырыла. Шәкертләр тарафыннан ике пәрдәлек «Үги кыз» әсәре куела, әдәбият бүлеме башкарыла. Шәкертләр һәм яшьләр мөгаллимә Рузия ханым карамагында өсләренә йөкләнгән рольләрен осталык белән җиренә җиткереп башкаралар, алкышларга күмеләләр. Кичәдән соң кунакларга чәй бирелә. Кунаклар яшьләр һәм балаларга милли тәрбия бирү турында фикерләрен әйтәләр, аларның уңышларыннан канәгать булуларын белдерәләр (Мохбир, 1943: 2).

5–9 октябрьдә вәкилләр хөрмәтенә Кижудагы милләттәшләр тарафыннан хосусый рәвештә табын мәҗлесләре үткәрелә. 9 октябрьдә вәкилләрне озату кичәсе оештырыла. Чит илдә торгызылган мәчет-мәктәп бинасының милли барлыкны саклауда уйнаячак роленә карата сүзләр сөйләнелә. Мәктәп ачудан тыш, шәкертләрне дәреслекләр белән тәэмин итү мәсьәләсе күтәрелә. Мәркәз нәшрият фонды файдасына 440 иена һәм япон гаскәрләре файдасына 1017 иена иганә тупланыла. Шундый бәйрәм шартларында төрле җирләрдән килгән хөрмәтле вәкилләр белән саубуллашу тантанасы уздырыла (Мохбир, 1943: 2).

Милли дәреслекләр белән тәэмин итү чыннан да бик мөһим мәсьәлә була, чөнки ул беренче чиратта матбугат, нәшрият эшен оештыруны таләп итә. Япон хөкүмәте әлеге башлангычларга киртәләр куймый. Нәтиҗәдә Ерак Көнчыгышта берничә милли нәшрият ачыла һәм уңышлы гына эшләп килә. Токио шәһәрендә оешкан «Матбугаи исламия» нәшрияте мәктәпләрне уку әсбаплары белән тәэмин итүдә зур роль уйный. Анда күбесенчә дини характердагы хезмәтләр чыгарылуына карамастан, әдәбият, музыка, грамматика буенча да аерым китаплар бастырыла. Мәсәлән, 1936 елда Токио Исламия матбугатында Кореяда то-

ручы мөселманнарның Кижу мәркәзе дини вә милли идарәсе тарафыннан башлангыч мәктәп өчен әлифба китабы бастырыла. Әлеге дәреслек Ерак Көнчыгышның төрле мәктәпләрендә кулланыла. М.А. Корбангалиев бу әлифбаның кереш сүзендә: «Өметсезлеккә төшмичә, чит илләрдә булып, [...] кем икәнеңне белмичә югалып китмәү өчен, тарихи бурычыбыз – милли телебезне, халкыбызны, динебезне саклау. Милли бу гарәп хәрефләре белән киләчәк буыныбызда ислам дөньясын беркетәдер һәм балаларыбызны Коръән укырга өйрәнүләре өчен мөмкинлек бирәдер. Шул сәбәпле бу максатларны тормышка ашыру нияте белән дини һәм милли идарәсе бу татарча әлифба китабын бастырды», – дип аңлатма бирә (Адутов, 2009: 50–51).

Моннан тыш, Кижудагы татар җәмгыяте һәм Токиодагы Ислам җәмгыятенең үзара берләшеп эшләүләре нәтиҗәсендә, 1934 елда Коръән, 1950 елда «Коръән тәфсире» нәшер ителә (Таһир, 1990: 178). Кижу шәһәре татар җәмгыяте тарафыннан чыгарылган төрле басмалар Ерак Көнчыгыштагы барлык мөселман мәхәлләләренә таратыла һәм Корея татарларының дини-милли тәрбия һәм белем бирү өлкәсенә зур игътибар бирүләре турында сөйли.

Кижу шәһәрендә торгызылган «Ногмания» мәчет-мәктәбенең ачылу тантанасына карата Мәркәз башкарма рәисе Әхмәдша әфәнде Гыйззәтуллинның карашлары да бик төпле һәм мәгънәле була. Аның фикеренчә, бу мәктәп Шәркый Азиядәге башка милли мәктәпләр белән уртак программа нигезендә эшләячәк һәм дәүләт тарафыннан биргән барлык хокуклардан файдаланачак. Шәркый Азия үлчәмендә моңа кадәр тарихта күрелмәгән бик зур көрәш алып барылган вакытта, япон хөкүмәте тарафыннан безнең рухани һәм милли-мәдәни истәлекләребезне тотар өчен кирәк булган бер бинаны торгызырга рөхсәт бирү һәм сугыш вакытында бу йортның ачылу тантанасына төрле җирдән вәкилләрнең килүләрен ул безнең халыкка карата күрсәтелгән зур бер хөрмәт дип атый. Азия дусларыбыздан туган бу дустанә мөнәсәбәт ачылу тантанасына килгән вәкилләрнең күңелләрен йомшарткандыр һәм япон хөкүмәтенә рәхмәт хисләрен тирәнәйткәндер, дип ышанып кала.

Әлеге «Ногмания» мәчет-мәктәбенең ачылуы Шәркый Азиядәге мәчет һәм мәктәпләр санының артуына булышлык итә, халкыбызның милли һәм дини ихтыяҗларын кәнагатьләндерүгә яңа бер адым булуын күрсәтә. «Мәсҗид-мәктәп «Ногмания»нең ачылу мәрасиме тәэсиратыннан» дип исемләнгән мәкалә авторы «Ногмания» мәчет-мәктәбенең чын мәгънәсендә һәр яктан җитеш итеп торгызылганын ассызыклый: «мәчет бүлмәсе кыйммәтле келәмнәр белән бизәлгән, кандилләр (*лампы*) белән гүзәлләнгәндер. Мәктәп бүлмәсе кирәк-яраклар белән тәэмин ителгән. Укытучылар өчен аерым бүлмәләр әзерләнгән. Мәчет аерым гөселханәсе белән тәэмин ителгән» (Мохбир, 1943: 3–4).

Мәктәпкә исем биргән бу шәхес кем булган соң?

Габделхак Ногман 1900 елда Самара вилаяте Бөгелмә өязе Кармалы волосте Әбәй авылында өязнең атаклы имамы Җамалетдиннең өченче улы булып дөньяга килә. Атасы Габделхакны үзе урынында имам итеп күрергә теләгән, шунлыктан башлангыч белемне үз мәктәбендә биргәннән соң, аны Чистай өязендәге атаклы Кизләү мәдрәсәсенә озата. Анда озак тотмыйча, Оренбургка илтеп, «Хөсәния» мәдрәсәсенә тапшыра. Соңгысында ике ел укыганнан соң, Габделхак атасының теләге буенча Казан шәһәрендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчә. Монда үзенең зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында булачак мөфти Галимҗан хәзрәт Баруди җәнабләренең игътибарын җәлеп итә. Габделхак әфәнде Галимҗан хәзрәтнең яраткан, якын шәкертләренең берсе булу дәрәҗәсенә ирешә. Ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганда, Русиядә революция башлана. Габделхак Ногман Казаннан кайту белән, Бөгелмәгә юнәлә. Милли шура рәисе булган тарихчы Һади әфәнде Атласи янында Земская управада сәркатип булып хезмәт итә башлый һәм, озак та тормый, Земская управа тарафыннан Бөгелмә өязенә мөгаллим-инструктор итеп билгеләнә.



Рәс. 3. Мәрхүм Габделхак әфәнде Ногман.
Чыганак: «Милли байрак» газетасы,
1941 ел, 14 февраль.

Революция тирәнәйгән саен, милли эшләрне дәвам итү мөмкинлеге чикләнә. Большевик гаскәрләре кергән һәр җирдән булдыра алган кешеләр качып китә башлый. 1919 елның май аенда шул качак дулкынына эләккән Габделхак әфәнде Чиләбегә килә. Ахырда Себер аркылы Урга (хәзерге Монголиядәге Улан-Батор шәһәре) шәһәрендә туктала. Ургага килү белән, андагы милләттәшләребез арасында имамлык һәм мөгаллимлек итә башлый (Габдулла Хәким, 1941: 2). Аерым мәгълүматлар буенча, 1919 елда ул Ерак Көнчыгыштагы аклар хәрәкәтенең атаклы эшлеклесе Унгерн гаскәрләрендә имам булып хезмәт итә (Усманова, Черникова, 2020: 663).

Ләкин Габделхак әфәнде кешегә хезмәт итеп кенә әллә ни алга китеп булмаганлыгын аңлый һәм үз эшен ачарга карар кыла, моның өчен Кумамото шәһәренә китә. Анда уңышлы сәүдә итә башлый. 1926 елны Хайларга барып, Шәмсенур туташ Тарпищевага никахлана. Шәмсенур Ногманова Ерак Көнчыгышта билгеле ханым була. Ул Кижу шәһәренең төрек-татар җәмгыятеннән Идел-Урал төрки-татарларның I Ерак Көнчыгыш съездына (1935 ел) вәкил итеп сайлана (Усманова, Черникова, 2020: 681).

1927 елда гаиләсе белән Кореяның Кижу шәһәренә күчкәч, Габделхак әфәнде, кибет ачып, зуррак күләмдә сәүдә итүгә керешә. Үзе өчен байлык туплау белән генә гомерен уздырмыйча, даими рәвештә милли оешма тормышына да ярдәм итеп тора. Кижудагы беренче оешманы барлыкка китергәндә, ул зур булышлыклар күрсәтә. Имамлык эшләрен өстенә алуы, милли тормышка хезмәт итүе белән генә чикләнмичә, туган илләреннән читтә туган балаларга дини-милли тәрбия бирү эшен дә башкара. Кижу халкы өчен өч айлык курс ачып дәрес бирә, дини вәгазьләр сөйли.

1933 елның ахырында Ерак Шәрыкка татар мөһаҗирләренең милли җитәкчесе Гаяз Ихакый килә. Халкыбыз берләшү, мәркәзләшүгә омтылып, корылтайлар җыя. Бу чорда Габделхак әфәнде халкыбызның милләтче катлавы эчендә атлый, матди ярдәме белән булыша. 1935 елның май аенда уздырылган Корылтай мәҗлесендә Габделхак әфәнде Кижудан вәкил булып килә һәм корылтай мәҗлесендә мәгариф комиссиясенең әгъзасы итеп сайлана. Ерак Шәрыктагы халкыбызны берләштергән Беренче Ерак Шәрык корылтаенда Габделхак әфәнде үзенең хатыны Шәмсенур ханым бергәләп катнаша. Фикерләре белән хәят фондының нигезен төзүгә өлеш кертә, корылтай тарафыннан мәркәз милли шөгъбәсенең әгъзасы итеп сайлана.

Бергәләп туктаусыз эшләү нәтиҗәсендә, Габделхак әфәнде белән Шәмсенур ханым соңгы елларда зур дәүләткә ия булалар. Кижуда берничә кибеткә хуҗа булу өстенә, Хайларда һәм Кобеда йортлар сатып алалар. Милли оешмага иганәләре белән булышып торалар. Аларның матди ярдәме белән Харбинда «Хәйрия хәяте»нә нигез салына. Хайлардагы «Җәмгыять хәйриясе» һәм Тәнзиндәге хәйрия эшләрендә Габделхак Ногман ярдәме зур була. Актык минутлары якынлашканда, үз теле белән васыять яздырган мәрхүм Габделхак әфәнде Ерак Шәрыктагы хәйрия эшләренә, Төркиядәге фәкыйрьләргә һәм япон даирәләренә зур иганәләр калдыра (Габдулла Хәким 1941: 2–3). Аның хатыны иренең васыятьләрен тулысынча башкарып чыга. Моңа дәлил итеп, аның исеменә «Милли байрак» газетасы идарәсенннән җибәрелгән рәхмәт хатын күрсәтергә мөмкин. Шәмсенур ханым үз чиратында «Милли байрак» газетасының чит җирләрдә яшәгән татарларның барлыгын, кыйбласын һәм миллилеген саклаудагы зур ролен ассызыклый. Габделхак Ногман исеменнән ул газета фондына 400 иена һәм милли мәркәз фондына 100 иена иганә тапшыра (Шәмсенур Ногман, 1941: 2).

Габдулла Ногманның вафаты Ерак Көнчыгыш мөселманнары өчен зур һәм вакытсыз югалту була, чөнки аның чит җирлектә милли үзлекне, милли мохитне саклап калуда роле зур була. Югары дәрәҗәләргә ирешүенә карамыйча, ул үзенең барлыгы белән милләте һәм аның киләчәге өчен янып йөргән шәхес булып тарихта кала. 37 көнлек каты авырудан соң, 1941 елның 13 гыйнварында Габдулла Ногман вафат була. Мәрхүмнең җеназасына һәм аны соңгы юлга озатырга Кижуда яшәүче бөтен милләттәшләр, һәм хәтта башка шәһәрләрдә яшәүче аерым затлар да килә. Кижу зиратында җирләнгән атаклы сәүдәгәрнең

һәм иганәченең исеме һәм эшләгән эшләре онытылмый. Аның исеме белән мәчет-мәктәпне атау моның ачык мисалы.

«Милли Байрак» газетасында бу мәчет-мәктәп турындагы мәгълүматлар 1944 ел белән тәмамлана. 1944 елда чыккан мәкаләләр әлеге мәктәпнең Кижу Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте тормышында зур роль уйнавы турында сөйли. «Ногмания» мәктәбе бинасында идарәнең гомуми җыелышлары, зур бәйрәмнәре (мәсәлән, «Тукай бәйрәме»), төрле курслар уздырыла. Җыелышларда рәхмәт сүзләреннән тыш, балаларны милли мәктәпкә бирү һәм мәктәпнең матди яшәешенә ярдәм итү мәсьәләләре еш күтәрелә. Кижу мәктәбенә багышланган мәкаләләрне өйрәнү төрле елларда уку елының башлану һәм имтихан алу вакытларының төрле булуын күрсәтә. Мәсәлән, 1936–1937 уку елында имтиханнар март аенда, ә 1937–1938 һәм 1942–1943 елларда июль аенда башлана. Бу төрлелекнең сәбәпләре әлегә билгесез. Һәр уку елы алдыннан дога мәҗлесе уздырылган. Мәсәлән, 1943–1944 уку елында «Ногмания»дә укулар башлану уңаеннан дога мәҗлесе 2 август көнне була, ә уку елы үзе 21 августтан гына башланып китә. Әлеге төрлелекне бетерү уңаеннан, Кижу төрек-татар җәмгыяте яңа, ягъни 1945 уку елыннан мәктәптә укуларны япон мәктәпләре белән бергә башлап китү турында игълан итә (Мохбир, 1944: 3). Билгеле булганча, Япониядә уку елы 1 апрельдән башлана. Кызганычка каршы, 1945 уку елы буенча мәгълүматлар билгесез, һәм без әлеге фактка ачыклык кертә алмыйбыз.

Балалар санына һәм уку тәртипләренә килгәндә, «Милли байрак» газетасы материалларына таянып кына төгәл мәгълүматлар табу мөмкин түгел. Мәсәлән, 1936–1937 уку елы тәмамлану уңаеннан төшерелгән фоторәсемдә биш укучыны күреп була. 1937–1938 уку елы буенча өч икенче сыйныф укучысы, бер өченче сыйныф укучысы һәм бер дүртенче сыйныф укучысы турында белешмәләр һәм аларның исемнәре китерелгән мәгълүмат бар. Шул ук көнне төшерелгән фоторәсем дә моңа дәлил булып тора. 1944 уку елында балалар саны бераз арта: ике баланың хәзерлек сыйныфыннан беренче сыйныфка, бер укучының өченче сыйныфка, өч укучының дүртенче, бер укучының бишенче сыйныфка, өч укучының алтынчы сыйныфка күчүләре һәм бер укучының шәһадәтнамә алуы турында белешмәләр бирелә. Аларның кайберләре беренче дәрәҗәдәге «Рәхмәт кәгазьләре» белән бүләкләнә.

Уку тәртибенә килгәндә, «Ногмания» мәктәбендә сәгать иртәнге 9 дан көндезге 1гә кадәр дәресләр татар телендә, шуннан соң ике сәгать дәвамында (көндезге 3 кә кадәр) япон телендә үткәрелгән. Мәктәпнең укыту программасында ислам дине, татар халкы тарихы, арифметика, ана теле һәм япон теле бар. Моннан тыш, Кижу Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте идарәсе карамагында эшләп килгән «Ногмания» мәктәбе бинасында барлык теләүчеләр өчен япон телендә кичке курслар оештырылган. Ул һәр дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе һәм шимбә көннәрендә сәгать кичке 7 дән 9 га кадәр уздырыла торган була (Мохбир, 1944: 3). «Милли Байрак» газетасының соңгы номеры 1945 елның мартында чыга, шунлыктан без әлеге мәктәпнең моннан

соңгы эшчәнлеген бу чыганактан белә алмыйбыз. Кызганычка каршы, аның тарихы өзелә. Бу 1945 елда Кореяның япон карамагыннан азат ителүе һәм икегә (Көньяк һәм Төньяк) бүленеп, ике якның бер-берсенә каршы сугыш башлавы белән бәйле. Кореяга килеп төпләнгән татарлар әлеге афәтләрдән котылыр өчен, төзегән биналарын, йортларын, ачкан сәүдәләрен һәм җайлашкан тормышларын ташлап, яңадан дөньяның төрле почмакларына сибелергә мәҗбүр булалар. Мөгаен, «Ногмания» мәчет-мәктәбе дә бу дулкын астына эләккәндер.




Рәс. 4. Кижу татарларының Г.Исхакый белән очрашулары (Usmanova, 2007)

Шулай итеп, без мөһаҗирлектә яшәүче милләттәшләребез мәгарифенең татар халкының гасырлар буе оешкан мәгариф традицияләре нигезендә дәвам итүен күрәбез. Бу иң беренче чиратта белем бирү һәм тәрбия системасының ислам кыйммәтләренә нигезләнүе белән бәйле. Татар кешесе бер мәхәллә белән яшәп, үз мәгариф учагын булдыра һәм үз көче, акчасы белән аны тота. Төп максат – татар милләтен, гореф-гадәтләрен, телне саклап калу һәм үстерүдән гыйбарәт була. Шул ук вакытта япон хөкүмәтенең татар мөһаҗирләренең белем алу мөмкинлекләрен чикләмичә, аларга күп кенә уңайлыклар тудыруын да искә алырга кирәк. Мал туплаган аерым шәхесләр, мөселман кешесе кануннарыннан тайпылмыйча, төрек-татар җәмгыятләренә матди ярдәм күрсәтәләр. Шуларның берсе – атаклы сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе Габделхак Ногман була. Аның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге һәм мирасы милләттәшләре арасында югары бәяләнә. Мөһаҗирлектә татар җәмгыятьләре тарафыннан оештырылган уку йортлары татар халкының зур казанышы һәм горурлыгы. Без аларны белергә, барларга һәм онытмаска тиешбез.

## ЧЫГАНАКЛАР

Мохбир. Кижу мәктәбендә // Милли байрак. 1937. 23 апрель.

Мохбир. Милли мәктәп тормышыннан (Кижу вә Нагоя мәктәпләрендә) // Милли байрак. 1938. 5 август.

Мохбир. Кижуда имтихан // Милли байрак. 1942. 28 апрель.

Мохбир. Мәсҗид-мәктәп «Ногмания»нең ачылу мәрасиме тәэсиратыннан // Милли Байрак. 1943. 20 октябрь

Мохбир. Мәсҗид вә мәктәбе «Ногмания»нең ачылу мәрасиме // Милли байрак. 1943. 10 ноябрь.

Мохбир. Кижу җәмгыяте хәбәрләреннән // Милли Байрак. 1944. 20 октябрь.

Хәким Габдулла. Мәрхүм Габделхак әфәнде Ногманның тормыш юлы // Милли Байрак. 1941. 14 февраль.

Шәмсенур Ногман. «Милли Байрак» фондына // Милли Байрак. 1941. 14 февраль.

## ӘДӘБИЯТ

*Адутов Р.М.* В стране самураев: татарская диаспора и мусульманские школы Японии // Минбар. 2009. № 2(4). С. 46–53.

*Гайнутдинов Д.* Как в Стране утренней свежести появилась татарская диаспора? URL: https://islam-today.ru/istoria/kak-v-strane-utrennej-svezesti-poavilas-tatarskaa-diaspora/ (мөрәҗәгать итү датасы: 24.04.2023)

*Кәримуллин Ә.Г.* Корея татарлары. URL: http://beznenmiras.ru/news/redakciya-khabarlare/koreyada-tatarlar (мөрәҗәгать итү датасы: 24.04.2023)

*Мәхмүт Таһир*. Татарлар Кореяда // Казан утлары. 1990. №7. Б.178–179.

*Мортазина Л.Р.* «Милли байрак» газетасында мәгариф мәсьәләләре // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х.Миннуллина, А.Ф.Ганиева, Л.Р.Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. С. 263–267.

*Усманова Л.Р.* Тюрко-татарская эмиграция в Северо-Восточной Азии начала XX в. // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2005. №1. С. 92–100.

*Усманова Л.Р., Черникова Л.П.* «Ориентировка НКВД» по тюрко-татарской эмиграции в Китае и Японии // Общество и государство в Китае. 2020. №34. С. 628–701.

*Usmanova L.* The Türk-Tatar Diaspora in Northeast Asia. Transformation of Consciousness: A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s. Tokyo: Rakudasha, 2007.

**Автор турында белешмә:** Садыйков Шамил Фәнис улы, педагогика фәннәре кандидаты, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); mergen777@mail.ru

*Редакциягә керде 27.04.2023* *Кабул ителде 31.05.2023*

# МЕЧЕТЬ-МЕКТЕБ «НУГМАНИЯ» В ГОРОДЕ СЕУЛЕ И ЕЕ МЕЦЕНАТ ГАБДУЛХАК НУГМАН

***Ш.Ф. Садыков***

*Институт истории им.Ш.Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*mergen777@mail.ru*

В статье, опираясь на материалы татарской газеты «Милли Байрак», автор приводит сведения о деятельности мечети-мектеб «Нугмания», находившейся в городе Сеуле (Корея), и ее меценате Габдулхаке Нугмане. Эта мечеть-мектеб, основанная в 1926 г., долгое время являлась главным центром просвещения корейских татар. Она находилась в ведении правления культурного общества волго-уральских тюрко-татар города Кейджо. Информация о ее деятельности прослеживается лишь до 1944 г. В газетных статьях, наряду с названием Сеула, зачастую используется его японское произношение Кейджо. На основе проведенного исследования дается оценка состояния национального образования корейских татар, осуществляется анализ программ обучения, учебных пособий и внутреннего распорядка в школе. Автор выявил имена отдельных педагогов, меценатов, общественных деятелей. Им раскрыта история создания школы. Публикация новой информации, различных мнений, отдельных фотографий, связанных со школой, помогает раскрыть особенности развития татарского народа. Изучение истории татар в эмиграции является важной и актуальной работой по накоплению, изучению и возвращению богатого культурного наследия этой этнической общности.

**Ключевые слова:** Кэйджо, Габдулхак Нугман, школа «Нугмания», газета «Милли Байрак», нация, татарское образование, эмиграция.

**Для цитирования:** *Садыков Ш.Ф.* Сеул шәһәрендәге «Ногмания» мәчет-мәктәбе һәм аның иганәчесе Габделхак Ногман // Историческая этнология. 2023. Т. 8. № 1. С. 125–140. DOI: 10.22378/he.2023-8-1.125-140

**Сведения об авторе:** Садыков Шамиль Фанисович, кандидат педагогических наук, старший научный сотрудник Центра истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); mergen777@mail.ru

*Поступила 27.04.2023* *Принята к публикации 31.05.2023*

# MOSQUE-MEKTEB "NUGMANIA" IN THE SEOUL CITY AND ITS PATRON GABDULKHAK NUGMAN

***Sh.F. Sadykov***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*mergen777@mail.ru*

At present, Tatars can be found anywhere in the world, and each of them has their own story and different reasons for relocation to a new territory. Wherever fate takes Tatar people, the first priority for them is to unite with their compatriots, brothers in faith, organize a Muslim parish. This trait helped the Tatar people to preserve their self-awareness, identity, religion, and native language in different historical periods. The Tatars who relocated to Korea are no exception to these rule. This article, based on the materials of the newspaper *Milli Bayrak*, provides information about the activities of the mosque-mekteb *Nugmaniya* of the Seoul city and its philanthropist Gabdulkhak Nugman. Founded in 1926, the mekteb-mosque served as the main educational center for Korean Tatars for a long while. It was administered by the board of the Volga-Ural Turkic Tatars' Cultural Society of the city of Keijo. Information about its activities can be traced only until 1944. Along with the name Seoul, its Japanese pronunciation Keijo is commonly used in newspaper articles.

Today, the study of the history of our countrymen in exile is an important and relevant work in the field of accumulation, study and return of the rich cultural heritage of the Tatars. On the basis of these data, we can get acquainted with the state of the national education of the Korean Tatars, educational programs, the internal procedures of the school and teaching aids. In addition, the author has identified the names of individual teachers, patrons, public figures and has provided insights into the history of creating the school. The publication of new information, different opinions, individual photographs related to the school help to further reveal the essence and specifics of the Tatar people's development.

**Keywords:** Keijo, Gabdulkhak Nugman, "Nugmania" school, "Milli Bayrak" newspaper, nation, Tatar education, emigration.

**For citation:** Sadykov Sh.F. (2023) Mosque-mekteb "Nugmania" in the Seoul city and its patron Gabdulkhak Nugman. *Istoricheskaya etnologiya* [Historical Ethnology]. Vol. 8. No. 1: 125–140. DOI: 10.22378/he.2023-8-1.125-140 (In Tat.)

## REFERENCES

Adutov R.M. (2009) In the land of the Samurai: the Tatar diaspora and Muslim schools in Japan. *Minbar* [Minbar]. No. 2(4): 46–53. (In Russ.)

Gaynutdinov D. How did the Tatar diaspora appear in the Land of Morning Calm? URL: https://islam-today.ru/istoria/kak-v-strane-utrennej-svezesti-poavilas-tatarskaa-diaspora/ (accessed: 24.04.2023) (In Russ.)

Karimullin A.G. Korea Tatars. URL: http://beznenmiras.ru/news/redakciya-khabarlare /koreyada-tatarlar (accessed: 24.04.2023) (In Tat.)

Makhmut Takhir. (1990) Korea Tatars. *Kazan utlary* [Lights of Kazan]. No. 7: 178–179. (In Tat.)

Mortazina L.R. (2018) Educational issues in “Milli Bayrak” newspaper. In: *Gayaz Iskhaki and the national revival of the Tatars at the beginning of the 20th century: Materials of the international conference dedicated to the 140th anniversary of the birth of G. Iskhaki*. Minnullina F.Kh., Ganiev A.F., Nadyrshina L.R. (eds). Kazan: Institute of Language, Literature and Arts Publ: 263–267. (In Tat.)

Usmanova L.R. (2005) Turko-Tatar emigration in Northeast Asia at the beginning of the 20th century. *Gasyrlar avazy* [Echo of Centuries]. No. 1: 92–100. (In Russ.)

Usmanova L. (2007) The Türk-Tatar Diaspora in Northeast Asia. Transformation of Consciousness: A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s. Tokyo: Rakudasha.

Usmanova L.R., Chernikova L.P. (2020) “Orientation of the NKVD” on the Turkic-Tatar emigration in China and Japan. *Obshchestvo i gosudarstvo v Kitae* [Society and the State in China]. No. 34: 628–701. (In Russ.)

**About the author:** Shamil F. Sadykov, Cand. Sc. (Pedagogy), Senior Research Fellow of the Center of History and Theory of National Education, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); mergen777@mail.ru

*Received April 27, 2023* *Accepted for publication May 31, 2023*